
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
РУКОВОДИТЕЛЬ
СТАРОКУРМАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО
КОМИТЕТА
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

423733, село Старое Курмашево,
ул. Центральная, дом 29, Тел. 3-44-56
Email: skur-akt@yandex.ru



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КОРМАШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ЖИТӘКЧЕСЕ

423733, Иске Кормаш авылы, Үзәк ур.,
29 нчы йорт. Тел.3-44-56
Email: skur-akt@yandex.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
«22”январь 2026 ел

КАРАР
№6

Актаныш муниципаль районының Иске Кормаш авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннарны һәм хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итәргә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү турында

2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы «Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында», 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан «Республикасы территориясендә хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2019 елның 30 декабрендәге 1275 номерлы карары, Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге Уставы нигезендә, муниципаль берәмлек территориясендә хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында, Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Актаныш муниципаль районының Иске Кормаш авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннар итеп билгеләргә:

- балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары; актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар;

- җәмәгать территорияләре (парклар, скверлар, массакүләм ял итү урыннары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буйлары);

- мәгариф оешмалары һәм сәламәтлек саклау оешмалары, мәдәният һәм сәнгать объектлары янындагы территорияләр;

- җәмәгать туклануы оешмалары, сәүдә объектлары янындагы территорияләр;

- хайваннарны йөртү һәм өйрәтү мәйданчыклары;

- җылылык челтәрләре һәм калдыклар туплау урыннары (мәйданчыклары) чикләрендәге территорияләр;

- зиратлар һәм мемориаль зоналар.

2. Актаныш муниципаль районының Иске Кормаш авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесен Иске Кормаш авыл җирлеге территориясендәге хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итәргә вәкаләтле зат итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Актаныш муниципаль районы
Иске Кормаш авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Д.Р.Вәлиева